**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
22.02.2024

Казан ш.

**БОЕРЫК**
№ 197-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 6 ноябрендәге 794-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кулланучыга республика башкарма хакимияте органы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең үрнәк тәртибен раслау турында» 2012 елның 08 декабрендәге 1068 номерлы карарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 6 ноябрендәге 794-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 25 октябрендәге 980-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибендә:

1 бүлектә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта:

1 пунктчада:

беренче абзацта «учреждениеләр һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга,

«күрсәтелгән органнар һәм оешмалар» сүзләрен «аның территориаль органнары яисә аңа буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «һәм аның территориаль идарәләре» сүзләрен «, аның территориаль органнары һәм аңа буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «территориаль идарәсенең» сүзләрен «территориаль органның, Министрлыкка буйсынган оешманың» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.5 пунктта «2.10» саннарын «2.11» саннарына алмаштырырга;

2.9 пунктта «2.3 һәм 2.5 пунктларында» сүзләрен «2.8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Министрлык тарафыннан төгәл булмаган белешмәләр бирелгән очракта, файдаланучының язма гаризасы буенча, ул мотивлаштырылган булырга тиеш, Министрлык булган төгәлсезлекләрне юкка чыгара.»;

2.11 пунктның 6 пунктчасындагы беренче абзацта «аның территориаль идарәләренең» сүзләрен «аңа караган территориаль органнарның» сүзләренә алмаштырырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков